| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

КАРАР　　　　　　　　　　　　　　　　　　　РЕШЕНИЕ

№ 45/7　　　　　　　　　　　　　　　　　　　15 ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыены үткәрү һәм әзерлек тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советы 2019 елның 10 октябре карары белән расланган “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыены үткәрү һәм әзерлек тәртибе турындагы нигезләмә” нең 3.1 пунктына абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

“Граждан нигезле сәбәпләр (сәламәтлеге, инвалидлыгы һ.б.) буенча гражданнар җыенында катнаша алмаса, гражданинның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аның теркәлү урыны (яшәү урыны), шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте, түләү суммасы күләме, льготниклар категориясенә керүен, күрсәткән шәхси гаризасы нигезендә, аның тавышы, гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен санаганда исәпкә алына.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru). урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Карар үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы:　　　　　А. А. Мөхәррәмов